Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

17 июнь 2021 ел № 57

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына чиста табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында нигезләмә хакында» 2014 елның 3 июлендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына чиста табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында нигезләмә хакында» 2014 елның 3 июлендәге 391 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 200 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. муниципаль унитар предприятиеләрнең Әлмәт муниципаль районы бюджетына күчерү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымтада салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләгәннән соң калган табыш өлешеннән «Әлмәт муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле чиста табыш чараларын исәпләү»не түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Күрсәткеч | Күләме, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Хисап чорының чиста табышы (зыян) (финанс нәтиҗәләре турында 2400 хисапның юлы), Россия Федерациясе Салым кодексының 251 статьясын исәпкә алып | |
| 2 | Билгеләнгән түләү ставкасы | 1% |
| 3 | Исәпләнгән түләү суммасы (стр. 1хстр.2) | |

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының икътисади

үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре (Минһаҗев И.М.), бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Грушин А.И.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов